**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Алмаз Гыймадиев хикәяләре**

**1. Алмаз Гыймадиевның «Телефонлы кәҗә» хикәясендә авылда иң абруйлы малай кем?**

а) «бишле»гә генә укучы;

ә) спортсмен;

б) кемнең телефоны иң кыйбатлысы — шул.

**2. Госманның башына нинди «гениаль идея» килеп төшә?**

а) иске телефонын кәҗә муенына асарга;

ә ) иске телефонына навигатор куярга;

б) навигатор куйган иске телефонын кәҗә корсагына ябыштырырга.

**3. Госман кәҗәне каян таба?**

а) балалар бакчасыннан;

ә) ашлык складыннан;

б) үзләренең абзарыннан.

**4. Хикәядәге юмор кайсы фикердә күренә?**

а) навигатор сүнгән;

ә) телефон төшеп калган;

б) кемдер мобильник урынына «Кәрәзле телефонның зыяны» дигән китап ябыштырып куйган.

**5. Рәмилә ALFның кем икәнен ничек белгән?**

а) хаталарыннан таныган;

ә) юри генә, беләм, ди;

б) кем икәнен белми.

**6.Кайсы гыйбарә «колорадо кортының кире Америкага очып китүе кебек гайре табигый хәл»гә туры килә?**

а) Диананың мине ачулануы;

ә) үзләренә кунакка чакыруы;

б) өй эшен күчерергә бирүе.

**7.Кем ул Диана?**

а) безнең авылдагы иң чибәр кыз;

ә) бөтен мәктәптә иң чибәр кыз;

б) малайлар белән дуслашырга яратучы кыз.

**8.Өстәл янында Рамай нинди хаталар ясый?**

а) кулларын юып, ананасны пычак белән кисеп ала;

ә) дүрт төрле салатны бергә болгатып, аш кашыгы белән ашый;

б) чәйне кашык белән әкрен генә болгата.

**9.Рамай өчен кызык музыка нинди?**

а) Моцартның «Җиденче симфония»се;

ә) Бетховенның «Егерме бишенче симфония»се;

б) «Скутер», «Мумий Троль», «Исхакхан» башкарган музыка.

**10.Рамай өчен иң кызыклы уен?**

а) корабль батырыш;

ә) мозаика төзү;

б) макрамэ.

**11.Хикәядә «интеллигент» сүзен кемгә карата кулланырга була?**

а ) Рамайга;

ә) Дианага;

б) Нәсимәгә.

**Ачкыч**

1. **Б**
2. **Б**
3. **А**
4. **Б**
5. **А**
6. **Ә**
7. **Ә**
8. **Ә**
9. **Б**
10. **А**
11. **Ә**

# Бәяләү

## 10-11 балл – “5”ле

## 8-9 балл – “4”ле

## 5-7 балл – “3”ле